**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасында катнашучыларның үзара хезмәттәшлеге тәртибен раслау турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасында катнашучыларның үзара хезмәттәшлеге тәртибен раслау турында» 2013 елның 24 маендагы ПУ-444 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2022 елның 15 сентябрендәге ПУ-645 номерлы Указы һәм Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 25 декабрендәге 906 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) атамасында «дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасында» сүзләрен «дәүләт һәм дәүләтнеке булмаган түләүсез юридик ярдәм системаларында» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 пунктта «дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасында» сүзләрен «дәүләт һәм дәүләтнеке булмаган түләүсез юридик ярдәм системаларында» сүзләренә алмаштырырга;

в) Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасында катнашучыларның үзара хезмәттәшлеге тәртибендә:

атамасында «дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасында» сүзләрен «дәүләт һәм дәүләтнеке булмаган түләүсез юридик ярдәм системаларында» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта:

«дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасында» сүзләрен «дәүләт һәм дәүләтнеке булмаган түләүсез юридик ярдәм системаларында» сүзләренә алмаштырырга;

«дәүләт системасы,» сүзләреннән соң «дәүләтнеке булмаган система,» сүзләрен өстәргә;

2 пунктта:

түбәндәге эчтәлекле яңа өченче абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча Вәкаләтле вәкил;»;

өченче – бишенче абзацларны тиешенчә дүртенче – алтынчы абзацлар дип санарга;

түбәндәге эчтәлекле $2^1$ пункты өстәргә:

«$2^1$. Татарстан Республикасы Законының 16 статьясы нигезендә дәүләтнеке булмаган системада түбәндәгеләр катнаша:

юридик клиникалар (студентлар консультация бюролары, студентлар юридик бюролары һәм башкалар);

дәүләтнеке булмаган түләүсез юридик ярдәм күрсәтү үзәкләре.»;

3 пунктта:

беренче абзацта «дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасында» сүзләрен «дәүләт һәм дәүләтнеке булмаган түләүсез юридик ярдәм системаларында» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктчасында «ведомствоара» сүзен төшереп калдырырга;

5 пунктта «(алар карамагындагы учреждениеләр тарафыннан тапшырылган күрсәткечләрне исәпкә алып),» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча Вәкаләтле вәкил,» сүзләрен, «дәүләт юридик бюросы» сүзләреннән соң «, юридик клиникалар, дәүләтнеке булмаган түләүсез юридик ярдәм күрсәтү үзәкләре» сүзләрен өстәргә;

6 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының,» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча Вәкаләтле вәкил,» сүзләрен, «һәм дәүләт юридик бюросы» сүзләрен «, дәүләт юридик бюросы, юридик клиникалар, дәүләтнеке булмаган түләүсез юридик ярдәм күрсәтү үзәкләре» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктта «һәм җыелма хисапны» сүзләрен «, җыелма хисапны» сүзләренә алмаштырырга, «дәүләт системасы кысаларында» сүзләреннән соң «, дәүләт системасы кысаларында нотариусларның түләүсез юридик ярдәм күрсәтүе турында Татарстан Республикасы Нотариаль палатасының җыелма хисабын» сүзләрен өстәргә, «28 февральдән дә соңга калмыйча» сүзләрен «15 майдан да соңга калмыйча» сүзләренә алмаштырырга;

$8^1$ пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$8^1$. Дәүләт юридик бюросы үз эшчәнлеген тормышка ашырганда Федераль законның 18 статьясындагы 5 һәм $5^1$ кисәкләрендә, 26 статьясындагы 2 кисәгендә күрсәтелгән килешүләр нигезендә адвокатлар һәм дәүләтнеке булмаган системада катнашучыларны түләүсез юридик ярдәм күрсәтүгә җәлеп итәргә хокуклы.».

2. Әлеге Указ рәсми бастырып чыгарылган көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ • АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2024 ел, 13 апрель
№ 265